Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Урта Чаллы авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ

«10» октябрь 2023 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге Урта Чаллы авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ**:**

1. 2024 елда Иске Чаллы авыл җирлеге Урта Чаллы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2000,00 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне башкару буенча түбәндәге эшләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Урта Чаллы торак пунктының сууткәргеч челтәрләрен күзәтү коеларын һәм янгын гидрантларын төзекләндереп алыштыру;
- Урта Чаллы торак пункты чикләрендәге юлларны ремонтлау.

Халык җыенында рәислек итүче: И.Н. Захаров

Иске Чаллы авыл җирлеге башлыгы И.Н. Захаров